Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Кибәк Иле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге
Кибәк Иле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

7 декабрь, 2019 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлегенең Кибәк Иле торак пунктында 2019 елның 7 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 180 (йөз сиксән).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 94 (туксан дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 93 (туксан өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 1 (бер).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2020 елда Питрәч муниципаль районы Кибәк Иле авыл җирлеге Кибәк Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлары, 2 төркем эшләмәүче инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, 80 яшьтән узган гражданнардан кала 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кибәк Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Кибәк Иле авыл җирлеге башлыгы И.М. Зиннуров